ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова,
422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы,
422575

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30

24.11.2025 ___ д. Канаш № 61

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 ст, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 ст, Канаш җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә, Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Канаш авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Вальков

Канаш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
24.11. 2025 ел № 61
карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен әлеге тәртип билгели

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 2026 елның 1нче гыйнварыннан 2026 елның 31нче мартына кадәр гражданнар җыенында катнашуга һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:
а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;
б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.
В) СВО катнашучылары

4. Аерым категория гражданнар өчен:
а) 1 төркем инвалидлар,
б) күп балалы гаиләләр,
в) көндезге уку йортлары студентлары,
түләү күләме гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.

4. Бер мәртәбә бирелә торган түләү турында хәбәрнамә (хәбәр итү) бланкы почта элемтәсе аша юллама бирү юлы белән гражданнар игътибарына җиткерелә.
Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

5. Гражданнардан алынган үзара салым акчалары Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә

6. Түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешма аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша (сылтама буенча) https://uslugi.tatarstan.ru/почта күчерүләрен гамәлгә ашыруга хокуклы оешмалар аша башкарыла.

7. Керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

8. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Канаш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
24.11. 2025 ел № 61
карарына

2 нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) №№ _____________

Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләү турында
Түләүче Ф.И.А.и. ________________________________________
Адрес: ________________________________________________________
Нигезендә ____________________________________________
Сезгә чараларны гамәлгә ашыруга бер тапкыр бирелә торган түләүне ___________ сум күләмендә________кадәр срокта түләргә кирәк,
түбәндәге реквизитлар буенча: ______________________________________
БИК алучы Банк _____________________________________
Сч. № _________________________________
Алучы. Сч № ________________________________________
ИНН _________________________________________
КПП _________________________________________
КБК _______________ _ ОКАТО__________________
Түләү билгеләмәсе __________________________________________
Җитәкчесе _________________ _______________________________
М. У. (имза) (имзаны киңәйтү)
- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -
Хәбәрнамә (Хәбәр) № _________________
үзара салым буенча бюджетка бер тапкыр түләнә торган түләү турында
________________ сум күләмендә.
Түләүченең Ф.И.А.и. __________________________________
Адрес: ___________________________________
Алдым «__» _________________ 20________ел _________________________
Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, өзек төпсәсе тутырыла һәм Канаш авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.